СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**

**Сеҗе авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 21 » август, 2019 ел № 100**

**“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Сеҗе авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүне әзерләү тәртибе турында " Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы федераль законның 25.1 статьясын, 2004 елның 27июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Сеҗе авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы статьяларын тормышка ашыру максатында Сеҗе авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 нче октябрендәге “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Сеҗе авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүне әзерләү тәртибе турында " гы 73 нче номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)1.6. пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа җирлек төзү турында халык инициативасын алга сөрү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия булган халык саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча»;

2) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 3.5. Гражданнар җыены торак пункт яки җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокукка ия. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә җыелу мөмкинлеге булмаса, әлеге торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

2.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Арча муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Сеже авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгына йөкләргә.

«Сеже авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы Г.М.Гибадуллина